Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Белкино авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Белкино авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ

13 ноябрь, 2019 ел № 3

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Белкино авыл җирлеге торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законының 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Белкино авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Түбәндәге торак пунктларда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Белкино авыл җирлегендә халык җыеннарын билгеләргә:

1.1. Белкино авылында. Халык җыенын ике этапта уздырырга:

- гражданнар җыенының беренче этабы 14 сәгать 00 минутта 2019 елның 28 ноябрендә авыл мәдәният йорты бинасында, Мәктәп урамы, 1 нче йорт адресы буенча үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Чишмә, Яшьләр, Мәктәп урамнары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

- 2019 елның 29 ноябрендә авыл мәдәният йорты бинасында халык җыенының икенче этабы Мәктәп урамы, 1 нче йорт адресы буенча үткәрергә. Җыенда катнашучылар исемлегенә Чокыр, Техник, Бистә урамнары буенча теркәлгән кешеләрне дә кертергә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Белкино авыл җирлеге Белкино торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 төркем инвалидларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау

«РИЗА» «КАРШЫ».

1.2. Чертово авылында. 2019 елның 28 ноябрендә Икмәк урамы буенча 4 номерлы йорт янында гражданнар җыенын 11 сәгать 00 минутта үткәрергә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез, 2020 елда Белкино авыл җирлеге Чертово торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Белкино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Питрәч муниципаль районы
Белкино авыл җирлеге башлыгы А. Н. Меньшов